**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16 декабря 2021 **Чирмешән авылы** **№ 496**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын раслау турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны даими йөртүне оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны даими йөртүне оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, шулай ук Чирмешән муниципаль районы халкының пассажирлар йөртүгә һәм транспорт хезмәтенә ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясе буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын раслау турында» 2019 елның 20 декабрендәге 535 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга һәм Татарстан

Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (http://pravo.tatarstan.ru/rus/cheremshan/oms/ik).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
җитәкчесе И.Н.Шәйдуллин